Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы өченче чакырылышының
унтугызынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы карары

2018 ел, 26 апрель № 146

Чикләрне үзгәртү инициативасын хуплау турында

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2018 ел, 23 гыйнвар, 31 нче номерлы "Муниципаль берәмлекләренең территориясенең чикләре үзгәрү турында инициатива күрсәтү турындагы" карарын, 2003 елның, 6 октябренең 131-ФЗ нче Федераль законның 12 нче статьясын, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында", Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясын, "Татарстан Республикасының җирле үзидарәләре турындагы" 2004 елның, 28 июленең 45 – ТРЗ номерлы Законның 13 статьясын, "Татарстан Республикасында административ-территориаль төзелеш турында" 2005 елның 7 декабренең 116 – ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын карап һәм "Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составына керүче "Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощак авылы җирлеге" муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча 2018 елның 11 нче апрелендә үткән халык алдында тыңлауларда белдерелгән Питрәч муниципаль районы халкы фикерен исәпкә алып Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. "Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составына керүче "Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощак авылы җирлеге" муниципаль берәмлеге түбәндәге кадастр номерлары белән: 16:33:080709:64; 16:33:080709:65; 16:33:080709:66; 16:33:080709:67; 16:33:080709:68; 16:33:080709:69, гомуми мәйданы 880911 кв.м. җир кишәрлеген Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләре өлешенә кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлларга.

3. Әлеге карарны "Вперёд" ("Алга") район гәҗитендә бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтына (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми бастырылган көннән көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүгә алуны Питрәч муниципаль районы Советының җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнештә, законнар, тәртип саклау һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов.